ГЛАВА
СТАРОЧЕКАЛДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧЕКАЛДА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.10.2023 Иске Чекалда авылы № 1

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чекалда торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кулегаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чекалда торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен Иске Чекалда авыл җирлеге Иске Чекалда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затларны һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү:

-тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү;

-трактор өчен өстәмә кайтаргыч җиһазлар сатып алу (өем, чапкыч).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы Иске Чекалда авылы, Чкалов урамы, 3 йорт, авыл клубы бинасында.

4. Иске Чекалда авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык П.М.Королев